МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.07.2016 г. Казань № 609 од

«Татарстан Республикасы туристлар
сувенирлары» ачык конкурсы үткәрү турында
нигезләмәне раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 7 июлендәге 1366-р номерлы карарын үтәү йөзеннән һәм Татарстан Республикасы халык сәнгати һөнәрчелеген һәм кәсепчелеген үстерүгә ярдәм итү максатларында
БОЕРАМ

1. «Татарстан Республикасы туристлар сувенирлары» ачык конкурсы үткәрү турында теркәлгән нигезләмәне расларга (алга таба - Нигезләмә).
2. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Министр А.М.Сибагатуллин

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының
26.07.2016 №609од
боерыгы белән расланды

**«Татарстан Республикасы туристлар сувенирлары»**
**ачык конкурсы үткәрү турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Татарстан Республикасы туристлар сувенирлары» ачык конкурсы үткәрү турында әлеге нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 7 июлендәге 1366-р номерлы карарын үтәү йөзеннән эшләнде.

1.2. «Татарстан Республикасы туристлар сувенирлары» ачык конкурсының (алга таба – конкурс) оештыручылары булып "Татарстан Республикасы Халык сәнгати һөнәрчелеген һәм кәсепчелеген үстерү үзәге" дәүләт бюджет учреждениесе һәм "Татарстан Республикасы Халык сәнгати һөнәрчелеге һәм кәсепчелеге палатасы" коммерцияләшмәгән партнерлыгы (алга таба - Оештыручылар) тора; Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Эшкуарлыкны үстерү департаменты, "Казан ярминкәсе" ачык акционерлык җәмгыяте, Казан шәһәренең Туристлык-мәгълүмат үзәге, "Татарстан Республикасы туристлык үсеше үзәге" автоном коммерцияләшмәгән оешма, Татарстан Республикасы туристлык агентлыклары ассоциациясе, "Татарстан Республикасы экскурсоводлар гильдиясе" ассоциациясе ярдәменә таянып үткәрелә.

1.3. Конкурста катнашырга оешмалар, шәхси эшмәкәрләр, юридик затлар, халык сәнгать һөнәрчелеге осталары, кәсепчелек белгечләре, дизайнерлар, рәссамнар, студентлар, укучылар һәм иҗат коллективлары (алга таба – гариза бирүчеләр) чакырыла.

## 2. Конкурс үткәрүнең максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурс үткәрүнең максатлары:

халык сәнгать һөнәрчелеген һәм кәсепчелеген торгызу һәм үстерү;

туристлар сувенирларын җитештерү һәм сату өлкәсе белән кызыксынган затларга һәм оешмаларга тәҗрибә уртаклашу өчен мәгълүмат һәм коммуникацияләр мәйданчыклары булдыру;

үз илебездә җитештерелә торган туристлар сувенирлары продукциясе базарын үстерү;

аеруча яхшы нәтиҗәләргә ирешкән халык сәнгать һөнәрчелеге осталарын һәм оешмаларны, сувенирлар продукциясен җитештерүчеләрне ачыклау һәм бүләкләү;

Татарстан Республикасының истәлекле урыннарын һәм традицияләрен популярлаштыру.

2.2. Конкурс үткәрүнең бурычлары:

туристлык үсеше өчен уңайлы территория буларак Татарстан Республикасының имиджын формалаштыру;

сувенирлар продукциясенең сыйфатын яхшырту һәм ассортиментын арттыру;

туристлык базарына туристлар өчен кыйммәтле булмаган сыйфатлы сувенир продукция белән чыгару;

туристлар сувенирлары продукциясе әзерләү һәм сату өлкәсенә хосусый-дәүләти партнерлык механизмын кертергә булышлык итү;

туристлар өчен сувенир продукциясен әзерли алучыларны ачыклау;

мәдәни мирасны, халык сәнгать һөнәрчелеген саклау һәм популярлаштыру һәм заманча сувенир продукция үсешен стимуллаштыру;

үз илебезнең һәм җирле җитештерүчеләрнең товарларының көндәшлеккә чыдамлылыгын арттыру һәм продукцияне сату базарын киңәйтү.

## 3. Конкурсны үткәрү шартлары

3.1. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

«Этнография сувениры»

«Гастрономия сувениры (эчемлекләр)»

«Гастрономия сувениры (ашамлык)»

«Шәһәр һәм туристлар маршруты сувениры»

«Музей сувениры»

«Сувенир - уенчык»

«Төргәк продукциясе».

3.2. Конкурска бер гариза бирүчедән 10 берәмлектән дә артык булмаган, авторның соңгы 2 елда ясалган эшләнмәләре (сувенир һәм бүләк продукция) (алга таба – Эшләнмәләр) кабул ителә.

Конкурска тәкъдим ителгән Эшләнмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә халык сәнгать һөнәрләре

традицион яшәгән урыннарны билгеләү турында” 2010 елның 12 мартындагы 130 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә халык сәнгать һөнәрләре традицион яшәгән урыннарның исемлегендәге халык сәнгать һөнәрчелеге эшләнмәсе яисә кәсепчелек эшчәнлеге, декоратив-гамәли сәнгатьнең төрле юнәлешләре буенча эшләнгән булырга тиеш. Моңа түбәндәгеләр керә:

агачка кисеп рәсем ясау
күнне һәм тирене сәнгати эшкәртү
киез
үсемлек материалларын үрү
кул белән нәфис чигеш
кул белән туку (бизәкләп, сугып)
нәфис керамика
сәйләннән үрү
корама тегү
музыка кораллары
челтәр үрү (энәләр, кечкенә ыргак белән бизәкләп бәйләү)
төрле материалдан курчаклар ясау, шул исәптән, милли киемнәрдән
каен тузы (тартмачыклар, савытлар, бизәнү әйберләре)
металлны нәфис эшкәртү
табигый һәм декоратив ташны нәфис эшкәртү

«Гастрономия сувенирлары (эчемлекләр)», «Гастрономия сувенирлары (ашамлыклар)» номинацияләрендә катнашу өчен законнар нигезендә бөтен санитар-эпидемиология таләпләренә җавап бирүче азык-төлек продукциясе кабул ителә.

## 4. Конкурсның бәяләү критерийлары

4.1. Конкурс түбәндәге бәяләү критерийлары нигезендә уздырыла:

тапшырылган Эшләнмәләрнең игълан ителгән Конкурс шартларына һәм номинацияләренә туры килүе;

Конкурска тапшырылган Эшләнмәләрдә Татарстан Республикасы территориясендәге тарихи-мәдәни кыйммәтләр һәм халык традицияләре нигезендә сәнгать-стиль үзенчәлекләрнең саклануы;

Эшләнмәнең иҗади үзгәлеге һәм оригиналь бизәлүе;

күпләп әзерли алу мөмкинлеге;

җитештерүнең икътисадый яктан максатка ярашканлыгы.

## 5. Конкурс жюриен формалаштыру һәм аның эш тәртибе

5.1. Конкурс жюрие «Татарстан Республикасы Халык сәнгати һөнәрчелеген һәм кәсепчелеген үстерү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба - Үзәк) боерыгы нигезендә 9 кешедән төзелә, алар арасына мәдәният, туристлык, мәгариф, сәнәгать, эшкуарлык учреждениеләре вәкилләре, сәнгать белгечләре, тарихчылар, шулай ук Татарстан Республикасының декоратив-гамәли сәнгать һәм халык сәнгать һөнәрчелеге өлкәсендәге белгечләре кертелә.

Конкурс нәтиҗәләре белән шәхси кызыксынган затлар (шул исәптән Конкурста катнашырга гариза бирүчеләр яки гариза биргән оешма штатында торучылар), яисә Конкурста катнашучылар тәэсир итә алырлык затлар Конкурс жюрие әгъзасы була алмый.

5.2. Конкурс жюрие утырышларда эшли. Конкурс жюрие әгъзаларының гомуми санының яртысыннан артыгы катнашса, утырыш тулы хокуклы санала.

5.3. Конкурс жюрие карары Конкурсның һәр критерие буенча балл кую һәм катнашучыларның рейтингын формалаштыру юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, жюри рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора.

5.4. Оештыру-техник эшчәнлекне координацияләү, утырышларны әзерләү һәм документлар эшен алып бару өчен Жюри рәисе җаваплы секретарьне билгели.

5.5. Жюриның җаваплы секретаре түбәндәге функцияләрне башкара:

Конкурсның беренче этабында гариза-анкеталарны кабул итә һәм керү тәртибе буенча теркәп куя;

Жюри утырышларында карaласы материалларны әзерли һәм аларны саклый;

Жюри утырышларының беркетмәсен тутыра.

Жюриның җаваплы секретаре жюри составына керми һәм утырышларда тавыш бирә алмый.

5.6. Конкурсның жюри утырышлары беркетмәләрен рәис өч көн эчендә раслый һәм алар расланганнан соң 5 эш көне эчендә Үзәкнең «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдәге рәсми сайтында урнаштырыла.

## 6. Конкурс үткәрү тәртибе

6.1. Конкурс өч этапта уздырыла:

беренче этап (1 -30 сентябрь, 2016 ел),

икенче этап (1 октябрь - 2 ноябрь, 2016 ел),

өченче этап (3 ноябрь - 7 ноябрь, 2016 ел).

6.2. Конкурс үткәрелү турындагы игълан 2016 елның 1 сентябреннән дә соңга калмыйча Үзәкнең «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдәге рәсми сайтында урнаштырыла, игъланда Конкурсның вакыты, урыны һәм тәртибе турында хәбәр ителә, гаризалар кабул итү башлану һәм тәгәлләнү вакыты күрсәтелә.

6.3. Конкурста катнашу өчен бер гариза да тапшырылмаган очракта Конкурс уздырылмаган булып таныла.

6.4. Конкурста катнашу өчен 2016 елның 1 сентябреннән 30 сентябренә кадәр Үзәккә (Казан ш., Мәскәү ур., 55 й., каб. 401, тел. 8 (843) 236-06-37) Конкурс гаризасын тапшырырга кирәк:

гаризалар – әлеге Тәртипнең 1 нче, 2 нче, 3 нче кушымталары формасындагы анкеталар,

Эшләнмәләрнең фоторәсемнәре һәм башкару техникасының тасвирламасы.

6.5. Конкурс гаризасы Үзәккә кәгазьгә бастырылган килеш тә, электрон форматта да тапшырыла.

6.6. Гариза бирүчене Конкурста катнаштырудан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

Конкурс гаризасы составында кирәкле документларның җитмәве,

Гариза-анкетада дөреслеккә туры килмәгән мәгълүмат булуы,

Конкурс гаризасының 2016 елның 30 сентябреннән соңрак тапшырылуы.

6.7. Әлеге Тәртип турында мәгълүмат, гариза-анкетаның формасы, шулай ук Конкурс нәтиҗәләре Үзәкнең «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдәге рәсми сайтында (www.remeslo.tatarstan.ru) урнаштырыла.

6.8. Конкурс гаризасын әзерләү чыгымнарын гариза бирүче үзе күтәрә.

6.9. Конкурс гаризаларын кабул ителгән тәртиптә Үзәк өч эш көне эчендә рәсмиләштерә.

6.10. Кабул итү срогыннан соңга калып кергән Конкурс гаризалары Конкурста катнаша алмый.

6.11. Конкурска катнашучылар исемлеге Конкурс гаризалары кабул итү тәмамланганнан соң 3 көн эчендә Конкурс жюрие утырышында игълан ителә.

6.12. Конкурска катнашучылар исемлеге Конкурс жюрие утырышы беркетмәсендә чагыла, беркетмә әлеге Тәртипнең 5.6 пункты нигезендә формалаштырыла һәм раслана.

6.13. Конкурсның беренче этабында сайлап алынган гаризалар 2016 елның 1 октябреннән 2 ноябренә кадәр Үзәкнең «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдәге рәсми сайтына урнаштырыла.

Әлеге этап кысаларында Конкурста катнашучы Эшләнмәне яклап смс тавыш бирү оештырыла.

6.14. Конкурсның өченче этабы (2016 елның 3 ноябреннән 7 ноябренә кадәр) Казан ш., Оренбург тракты, дом 8 нче йорт адресы буенча «Казан ярминкәсе» ачык акционерлык җәмгыяте биләмәләрендә - «АРТ - галерея. Казань - 2016» 8 нче заманча сәнгать, сынлы сәнгать һәм халык сәнгате һөнәрчелеге махсус күргәзмәсе кысаларында уздырыла. Биредә Конкурс жюрие Эшләнмәләрне 10 баллы шкала буенча (0дән 10га кадәр) әлеге Тәртипнең 3 бүлегендә билгеләнгән критерийлардан

чыгып, Конкурсның икенче этабындагы смс тавыш бирү нәтиҗәләрен дә исәпкә алып бәяли.

6.15. Һәр критерий буенча баллар суммасыннан чыгып жюри Конкурста катнашучыларның рейтингын төзи.

6.16. Жюри рейтинг нигезендә 2 көн эчендә җиңүчеләр исемлеген төзи, ул 3 көн эчендә Үзәкнең боерыгы белән раслана.

6.17. Конкурс җиңүчеләренең исемлеге расланганнан соң, 5 эш көне эчендә Үзәкнең «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдәге рәсми сайтына урнаштырыла һәм масскаүләм мәгълүмат чараларында басыла.

6.18. Конкурс нәтиҗәләре суд тәртибендә генә яңадан карала ала.

## 7. Җиңүчеләрне бүләкләү һәм акчалата бүләкләрне түлү тәртибе

7.1. Конкурсның өченче этабына үтүчеләрнең һәркайсы җиңүче дипломы белән бүләкләнә.

7.2. Конкурсның һәр номинациясенең җиңүчесе 50 000 сум күләмендә акчалата приз белән бүләкләнә, эшләнмәгә "Татарстан Республикасының иң яхшы туристлар сувенирлары" статусы бирелә.

7.3. Акчалата призлар Татарстан Республикасы бюджеты хисабыннан түләнә.

7.4. Конкурс җиңүчеләре "Татарстан Республикасының иң яхшы туристлар сувенирлары" статусын үз этикеткаларында, төргәкләрендә һәм реклама максатларында куллану хокукына ия булалар.

«Татарстан Республикасы туристлар сувенирлары» ачык конкурсы үткәрү турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

Форма

«Татарстан Республикасы туристлар сувенирлары»
ачык конкурсына катнашу өчен
**гариза – анкета**
*(физик затлар өчен)*

1. Авторның (авторларның) фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (тулысынча) _____

_____________________________________________________________________*

2. Туган көне _______________________________________________________

3. Өй адресы, телефоны _______________________________________________

_____________________________________________________________________

4. Паспорт (туу турында таныклык) ____________________________________

_____________________________________________________________________

5. Эшләнмә(ләр)нең характеристикасы:

Номинация__________________________________________________________

Эшләнмә(ләр)нең атамасы_____________________________________________

Гаризада күрсәтелгән эшләнмә(ләр)нең бәясе (сум) _______________________

Эшләнмә(ләр)нең ясалган елы _________________________________________

Эшләнмә(ләр)не ясау техникасы_______________________________________

6. E-mail, элемтә өчен телефон_________________________________________

* Гариза бирүче Әлеге гариза-анкетаны имзалап Оештыручыларга, "Персональ мәгълүматлар турында" 27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законга туры китереп, үзенең персональ мәгълүматын эшкәртергә рөхсәт бирә

**Гариза бирүче:**

___________________ (имза)

___________________ (имзаны ачыклау)

«Татарстан Республикасы туристлар сувенирлары» ачык конкурсы үткәрү турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

Форма

«Татарстан Республикасы туристлар сувенирлары»
ачык конкурсына катнашу өчен
**гариза – анкета**
*(шәхси эшмәкәрләр өчен)*

1. Шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (тулысынча)____________

_______________________________________________________________________

2. Теркәлү датасы, теркәүче орган, ИНН_________________________________

_______________________________________________________________________

3. Юридик адресы /Фактик адресы______________________________________

_______________________________________________________________________

4. E-mail, элемтә өчен телефон (факс) _____________________________________

5. Эшләнмә(ләр)нең характеристикасы:

Номинация_____________________________________________________________

Эшләнмә(ләр)нең атамасы_________________________________________________

Гаризада күрсәтелгән эшләнмә(ләр)нең бәясе (сум) ____________________________

Эшләнмә(ләр)нең ясалган елы ______________________________________________

Эшләнмә(ләр)не ясау техникасы____________________________________________

6. Серияләп җитештерелә торган продукциянең күпләп сату бәясе (сум)____________

**Шәхси эшмәкәр:** ________________ ____________________
(имза) (имзаны ачыклау)
м.п.(мөһер булса)

«Татарстан Республикасы туристлар сувенирлары» ачык конкурсы үткәрү турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

Форма

«Татарстан Республикасы туристлар сувенирлары»
ачык конкурсына катнашу өчен
**Гариза – анкета**
*(юридик затлар өчен)*

1. Юридик затның атамасы (тулысынча)________________________________________

_______________________________________________________________________________

2. Оештыру-хокукый форма____________________________________________________

3. Юридик адресы / Фактик адресы______ ______________________________________

_______________________________________________________________________________

4. E-mail, элемтә өчен телефон (факс) _______________________________________

_______________________________________________________________________________

5. Эшләнмә(ләр)нең характеристикасы:

Номинация______________________________________________________________________

Эшләнмә(ләр)нең атамасы________________________________________________________

Гаризада күрсәтелгән эшләнмә(ләр)нең бәясе (сум) ________________________________

Эшләнмә(ләр)нең ясалган елы ______________________________________________________

Эшләнмә(ләр)не ясау техникасы_____________________________________________________

6. Серияләп җитештерелә торган продукциянең күпләп сату бәясе (сум)_____________

**Гариза бирүченең җитәкчесе:** ________________ ______________________
(имза) (имзаны ачыклау)
м.п.(мөһер булса)